МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.05.2018 г.Казань № 363

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2018 елның 28 маенда теркәлде, № 4704

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифахнә-курортта дәвалануга юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 16 июлендәге 473 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифахнә-курортта дәвалавынуга юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифахнә-курортта дәвалануга юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2015 елның 16 июлендәге 473 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 10 августындагы 465 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифахнә-курортта дәвалануга юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Административ регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлекнең 1.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

«Аз керемле дип тану һәм дәүләт социаль ярдәме күрсәтү өчен керемнәрне исәпкә алу һәм гаиләнең җан башына туры килә торган керемен һәм ялгыз яшәүче гражданинның керемен исәпләү тәртибе турында» 2003 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 44-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2003, № 14, 1257 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре турында һәм мәгълүмат яклау турында» 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2006, № 31, 3448 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2006, № 31, 3451 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон), (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2011, № 15, 2036 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Инвалидларның хокуклары турында конвенция ратификацияләнүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 1 декабрендәге 419-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2014, № 49, 6928 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Указы (алга таба – 601 номерлы указ) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү өчен гаиләнең җан башына туры килә торган керемен һәм ялгыз яшәүче гражданинның керемен исәпләгәндә исәпкә алына торган керемнәрнең төрләре исемлеге турында» 2003 елның 20 августындагы 512 номерлы карары (алга таба – 512 номерлы карар) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2003, № 34, 3374 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының «Амбулатор шартларда медицина ярдәмен күрсәтүче медицина оешмаларында файдаланыла торган медицина документациясенең унификацияләнгән формаларын һәм аларны тутыру тәртипләрен раслау турында» 2014 елның 15 декабрендәге 834н номерлы боерыгы (алга таба – 834н номерлы боерык) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы http://www.pravo.gov.ru,2015);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы мәсьәләләре» 2007 елның 15 августындагы 388 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм

республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, № 33, 1178 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы карары (алга таба – 880 номерлы ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курортта дәвалауны тәэмин итү тәртибен раслау турында» 2011 елның 14 февралендәге 97 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларын шифаханә-курортта дәвалауны тәэмин итү тәртибе (алга таба – ТР МК 97 номерлы карары белән расланган Тәртип) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2011, № 18, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).»;

Административ регламентның 1 бүлегендәге 1.4 пунктның 1.4.1 пунктчасында:

«белешмәлек кушымтада» сүзләрен «6 нчы белешмәлек кушымтада» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле өченче абзац өстәргә:

«Шәхсән мөрәҗәгать иткәндә гаризаларны кабул итү графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, Идарәнең (бүлекнең) эш сәгатьләрендә, алар эчке эш тәртибе кагыйдәләрендә билгеләнә.»;

Административ регламентның 2 бүлегендәге таблицада «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының 2.4 пунктында түбәндәге эчтәлекле өченче абзац өстәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган.»;

Административ регламентның 2 бүлегендәге таблицада «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының 2.5 пунктында алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гаиләдәге һәр әгъзаның гариза биргән айдан алдагы өч ай өчен керемнәре турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондында белешмәләр булган түләүләрдән тыш).»;

Административ регламентның 2 бүлегендәге таблицада «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының 2.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек каналлары аша түбәндәге мәгълүматлар алына:

алына торган барлык төр пенсияләрнең һәм башка түләүләрнең күләме турында (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан) (пенсионер өчен);

опека (попечительлек) билгеләү һәм опекунның (попечительнең) баланы асраганга акча алуы турында (җирле үзидарә органнарыннан) (пенсионер өчен);

эшсез сыйфатында теркәлү, эшсезлек буенча пособие (стипендияләр һәм башка төрле түләүләр алу һәм аның күләме турында (Татарстан Республикасында халыкның мәшгульлек хезмәтләре дәүләт учреждениеләреннән) (алга таба – Халыкның мәшгульлек үзәкләре);

физик зат файдасына эш бирүче (иминиятләштерүче) тарафыннан түләнгән түләүләрнең һәм башка төрле бүләкләүләрнең суммасы турында (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан).

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Аталган белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмаларда, шул исәптән, мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алынырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүчедән югарыда санап үтелгән, дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, бүтән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалар карамагында булган документларны тапшыруын таләп итү рөхсәт ителми.

Документларны алу ысуллары һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны тапшыру тәртибе әлеге регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.

Мөрәҗәгать итүченең югарыда күрсәтелгән документларны тапшырмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.»;

Административ регламентның 2 бүлегендәге таблицада «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының 2.12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризаны тапшырганда һәм мондый хезмәтләр күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты – 15 минуттан артык түгел.

Дәүләт хезмәтен алучы аерым категорияләр өчен чират билгеләнмәгән.»;

Административ регламентның 2 бүлегендәге таблицада «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының 2.13 пунктында түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә килгән гарызнамә ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә.»;

Административ регламентның 4.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Идарә (бүлек) хезмәткәрләре тарафыннан Реламентның һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив-хокукый актларның нигезләмәләренең саклануын һәм үтәлүен агымдагы тикшереп тору Идарә (бүлек) җитәкчесе тарафыннан әлеге Регламентның нигезләмәләре саклануына һәм үтәлүенә тикшерүләр уздыру юлы белән гамәлгә ашырыла. Идарә (бүлек) җитәкчесенең карарлар кабул итүенә агымдагы контрольне оештыру тәртибе һәм формалары Министрлык аппаратының әлеге контрольлекне гамәлгә ашыру өчен вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан билгеләнә.»;

Административ регламентның 4.2 пунктының беренче абзацын түбәндәге

редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору Министрлык аппараты бүлегенең һәм Министрлыкның Татарстан Республикасы муниципаль районында яисә шәһәр округында Социаль яклау идарәсенең (бүлегенең) (алга таба – Идарә (бүлек)) әлеге тикшереп торуны гамәлгә ашыруга вәкаләтле вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла, аларның вәкаләтләре Министрлыкның структур бүлекчәсе турында нигезләмәдә һәм хезмәткәрләрнең вазыйфаи регламентларында билгеләнә.»;

Административ регламентның 5 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының (хезмәткәренең), яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү

5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар судка кадәр тәртиптә Идарәнең (бүлекнең) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата Идарә (бүлек) җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Үзәк яисә Идарә (бүлек) җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка министрның тикшерүдә тотучы урынбасары яисә министр исеменә тапшырыла.

Министр урынбасарының (министрның) карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына белдерелергә мөмкин.

Мөрәҗәгать итүче, шул исәптән түбәндәге очракларда да, шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гаризасын теркәү вакыты бозылганда;

дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты бозылганда;

мөрәҗәгать итүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документлар таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итеп алудан баш тартканда;

федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән бүтән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында нигезләр каралмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда;

дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында караламган түләү таләп ителгәндә;

дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи зат дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә тапшырылган документларда үзләре тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталрны төзәтүдән баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документларны бирү чоры яисә тәртибе бозылганда;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торганда, әгәр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм норматив хокукый актларында туктатып тору өчен нигезләр каралмаган булса.

5.2. Шикаять кәгазьдә язмача яки электрон рәвештә тапшырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять югары торучы органга (булган очракта) бирелә яисә, андый булмаган очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүче органның турыдан-туры җитәкчесе тарафыннан карала.

Дәүләт хезмәтен алучылар тарафыннан шикаять почта, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайтыннан (http://mtsz.tatar.ru), Татарстан Республикасы Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул иткәндә кабул итеп алынырга мөмкин.

5.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүче органга килгән шикаятьне карау чоры – аны теркәүгә алганнан соң унбиш эш көне эчендә һәм дәүләт хезмәте күрсәтүче органның мөрәҗәгать итүчедән документларны кабул итүдән баш тартуына яисә җибәрелгән басма хаталарын һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять белдерелгәндә яисә мондый төзәтмәләр кертүнең билгеләнгән вакыты бозылган очракта, – аны теркәүгә алганнан соңгы биш эш көне эчендә.

5.4. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә граждан хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәгән урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә мөмкин булган почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелгән карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органдагы вазыйфаи затның яисә дәүләт хезмәткәренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән ризалашмавын нигезләүче дәлилләр.

5.5. Шикаятькә шикаятьтә бәян ителгән хәлләрне раслый торган документларның күчермәләре теркәлергә мөмкин. Бу очракта шикаятьтә аңа теркәлә торган документларның исемлеге китерелә.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча әлеге Регламентның 5.1 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи зат түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда

дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында алуы каралмаган түләүләрне кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктның 1 һәм 2 пунктчаларында күрсәтелгән карарны кабул иткән көннән соңгы көннән соңга калмыйча мөрәҗәгать итүчегә язмача яки, аның ихтыярына карап, электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.7. Шикаятьне карау барышында яисә нәтиҗәсендә административ хокук бозу яки җинаять кылу билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны прокуратура органнарына кичекмәстән җибәрә.»;

Административ регламентның 5 нче кушымтасындагы блок-схемада «белешмәләр соратуны формалаштыра» сүзләрен «белешмәләрнең ведомствоара гарызнамәсен формалаштыра» сүзләренә алмаштырырга;

Административ регламентка кушымтаны (белешмәлекне) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифахнә-курортта дәвалануга юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 6 нчы кушымта (белешмәлек)

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПЕНСИОНЕРЛАРЫНЫҢ АЕРЫМ КАТЕГОРИЯЛӘРЕН ТАШЛАМАЛЫ ШАРТЛАРДА ШИФАХНӘ-КУРОРТТА ДӘВАЛАНУГА ЮЛЛАМА АЛУ ӨЧЕН ИСӘПКӘ КУЮ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ ХЕЗМӘТЕ КҮРСӘТҮ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ БУЛГАН ҺӘМ АНЫҢ ҮТӘЛҮЕН КОНТРОЛЬДӘ ТОТУЧЫ ОРГАННАР ҺӘМ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАР ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘЛӘР**

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында социаль яклау идарәләре (бүлекләре)

| Идарәнең (бүлекнең) аталышы | Телефоны | Адресы |
|---|---|---|
| Әгерҗе муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85551)<br>2-10-86<br>2-11-53 | 422230, Әгерҗе ш., Карл Маркс ур., 11а<br>Agreez.Usz@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Азнакай муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85592)<br>7-25-10<br>7-14-25 | 423300, Азнакай ш., Болгар ур., 9/2 й.<br>Usz.Azn@tatar.ru |
| Аксубай муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84344)<br>2-92-72,<br>2-92-74 | 423060, Аксубай ш.т.п., Мазилин ур., 2 й.<br>Usz.Aksubaevo@tatar.ru |
| Актаныш муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85552)<br>3-11-46<br>3-12-81 | 423740, Актаныш ав., Юбилей ур., 45.<br>Usz.Aktanysh@tatar.ru |
| Алексеевск муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84341)<br>2-41-40<br>2-46-46 | 422900, Алексеевск ш.т.п., Казаков ур., 8 й.<br>Usz.Alekseevsk@tatar.ru |
| Әлки муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84346)<br>2-08-90<br>2-08-80 | 422870, Базарлы Матак ав., Ленин ур., 9 й.<br>Usz.Alkeevo@tatar.ru |
| Әлмәт муниципаль районы социаль яклау идарәсе | (8553)<br>32-45-50,<br>43-82-15 | 423452, Әлмәт ш., Клара Цеткин ур., 54 а й.<br>Usz.Almet@tatar.ru |
| Апас муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84376)<br>2-12-84<br>2-10-81 | 422350, Апас ав., Шоссе ур., 5 й.<br>Usz.Apastovo@tatar.ru |
| Арча муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84366)<br>3-13-53<br>3-13-33 | 422000, Арча ш., Банк ур., 6 в й.<br>Usz.Arsk@tatar.ru |
| Әтнә муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84369)<br>2-16-60<br>2-10-84 | 422750, Олы Әтнә ав., Октябрь ур., 9 й.<br>Usz.Atnya@tatar.ru |
| Баулы муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85569)<br>5-10-50<br>5-66-81<br>5-66-78,<br>5-66-68 | 423930, Баулы ш., Җиңү мәйданы, 4 й.<br>usz.bavly@tatar.ru |
| Балтач муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84368)<br>2-44-78,<br>2-42-09,<br>2-50-57,<br>2-40-60 | 422250, Балтач ав., Һади Такташ ур., 3а й.<br>Usz.Baltasi@tatar.ru |
| Бөгелмә муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85594)<br>6-50-44,<br>6-55-70 | 423230, Бөгелмә ш., Стрелочная ур., 1 й.<br>Usz.Bugulma@tatar.ru |
| Буа муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84374)<br>3-32-10<br>3-55-29 | 422430, Буа ш., Ленин ур., 52 й.<br>Usz.Buinsk@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Югары Ослан муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84379)<br>2-17-57<br>2-13-01,<br>2-22-69 | 422570, Югары Ослан ав.,<br>Медгородок ур., 21 а<br>Usz.V-uslon@tatar.ru |
| Биектау муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84365)<br>2-32-43<br>2-32-52,<br>2-32-50,<br>2-32-53 | 422700, Биектау т.ю. ст пос.,<br>Профсоюз ур., 1а й.<br>Usz.Vgora@tatar.ru |
| Чүпрәле муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84375)<br>2-38-07<br>2-31-52<br>2-30-07 | 422470, Иске Чүпрәле ав.,<br>Үзәк ур., 15 й.<br>Drozh.Usz@tatar.ru |
| Алабуга муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85557)<br>7-84-66,<br>7-86-91 | 423600, Алабуга ш.,<br>Спас ур., 3 й.<br>Usz.Elabuga@tatar.ru |
| Зәй муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85558)<br>7-10-64<br>7-09-76<br>3-26-89 | 423520, Зәй ш., Рафиков ур.,<br>10 й.<br>Usz.Zainsk@tatar.ru |
| Яшел Үзән муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84371)<br>5-58-80<br>5-77-54<br>4-16-62 | 422540, Яшел Үзән ш., Карл<br>Маркс ур., 57 в<br>Usz.Zeldol@tatar.ru |
| Кайбыч муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84370)<br>2-11-12<br>2-15-57 | 422330, Зур Кайбыч ав.,<br>Кояшлы бульвар, 7 й.<br>Usz.Kaybicy@tatar.ru |
| Кама Тамагы муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84377)<br>2-15-57<br>2-12-69 | 422820, Кама Тамагы ш.т.п.,<br>К.Маркс ур., 2 й.<br>Usz.K-uste@tatar.ru |
| Кукмара муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84364)<br>2-84-76<br>2-64-65 | 422110, Кукмара ш.т.п.,<br>Ворошилов ур., 44 й.<br>Usz.Kukmor@tatar.ru |
| Лаеш муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84378)<br>2-49-70 | 422610, Лаеш ш.,<br>Беренче май ур., 35 й.<br>Osz.Laishevo@tatar.ru |
| Лениногорск муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85595)<br>5-07-51<br>6-02-26<br>5-50-03 | 423250, Лениногорск ш.,<br>Гагарин ур., 51 й.<br>Usz.Leninogorsk@tatar.ru |
| Мамадыш муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85563)<br>3-12-36<br>3-12-64 | 422190, Мамадыш ш.,<br>Совет ур., 10 й.<br>Usz.Mamadysh@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Менделеевск муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85549)<br>2-23-00<br>2-04-53 | 423650, Менделеевск ш.,<br>Бурмистров ур., 7а й.<br>Usz.Mendeleev@tatar.ru |
| Минзәлә муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85555)<br>3-26-59 | 423700, Минзәлә ш.,<br>Ленин ур., 80 й.<br>Usz.Menzelinsk@tatar.ru |
| Мөслим муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85556)<br>2-57-37<br>2-57-69 | 423970, Мөслим ав.,<br>Пушкин ур., 47 й.<br>Usz.Muslyumovo@tatar.ru |
| «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге социаль яклау идарәсе | (8552)<br>47-49-33 | 423805, Яр Чаллы ш.,<br>Кояшлы бульвар, 6 й.<br>Usz.Chelny@tatar.ru |
| Түбән Кама муниципаль районы социаль яклау идарәсе | (8555)<br>45-39-20<br>45-43-86<br>45-43-89<br>45-35-02 | 423570, Түбән Кама ш.,<br>Тынычлык проспекты, 60 й.<br>usznizhnekamck@tatar.ru |
| Яңа Чишмә муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84348)<br>2-41-18<br>2-41-42 | 423190, Яңа Чишмә ав.,<br>Ленин ур., 93 й.<br>Usz.Novoshesh@tatar.ru |
| Нурлат муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84345)<br>2-06-62<br>2-06-81<br>2-39-88 | 423040, Нурлат ш., Пушкин ур., 46 й.<br>Usz.Nurlat@tatar.ru |
| Питрәч муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84367)<br>3-06-68<br>3-06-72<br>3-00-15 | 422770, Питрәч ав.,<br>Совет ур., 20 й.<br>Usz.Pitriash@tatar.ru |
| Балык Бистәсе муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84361)<br>2-11-57<br>2-39-62 | 422650, Балык Бистәсе ав.,<br>Завод ур., 6а й.<br>Usz.R-sloboda@tatar.ru |
| Саба муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84362)<br>2-28-11<br>2-28-55 | 422060, Байлар Сабасы ш.т.п.,<br>Закир Йосыпов ур., 7 й.<br>Usz.Saby@tatar.ru |
| Сарман муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85559)<br>2-45-72<br>2-44-37 | 423350, Сарман ав.,<br>Куйбышев ур., 36 й.<br>Usz.Sarmanovo@tatar.ru |
| Спас муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84347)<br>3-00-00<br>3-08-98 | 422840, Болгар ш., Пионер ур., 21<br>Usz.Bolgar@tatar.ru |
| Тәтеш муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84373)<br>2-62-31 | 422370, Тәтеш ш., Ленин ур., 114 й.<br>Usz.Tetyushi@tatar.ru |

| | | |
|---|---|---|
| Тукай муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (8552)<br>70-00-57<br>70-13-41 | 423807, Чаллы ш.,<br>Есенин тыкрыгы, 1 й.<br>Usz.Tukaev@tatar.ru |
| Теләче муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84360)<br>2-18-56 | 422080, Теләче ав., Зур Тау ур., 5 й.<br>Usz.Tulachi@tatar.ru |
| Чирмешән муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84396)<br>2-57-05<br>2-29-38 | 423100, Чирмешән ав.,<br>Титов ур., 26 й.<br>Usz.Cheremshan@tatar.ru |
| Чистай муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (84342)<br>5-55-73<br>5-12-06 | 422980, Чистай ш.,<br>Урицкого ур., 45.<br>Usz.Chistopol@tatar.ru |
| Ютазы муниципаль районы социаль яклау бүлеге | (85593)<br>2-60-41 | 423950, Урыссу ш.т.п.,<br>Пушкин ур., 105/1<br>Usz.Utazy@tatar.ru |
| Казан ш. Авиатөзелеш районы социаль яклау бүлеге | (843)<br>571-58-00<br>570-06-31 | 420036 Казн ш., Тимирязев ур., 8 й.<br>Usz.Avia@tatar.ru |
| Казан ш. муниципаль берәмлегенең Вахитов районы социаль яклау бүлеге | (843)<br>238-10-55<br>238-41-91 | 420043 Казан ш., Вишневский ур., 10<br>Usz.Vahit@tatar.ru |
| Казан ш. муниципаль берәмлегенең Киров районы социаль яклау бүлеге | (843)<br>554-47-80<br>554- 74-57<br>554-22-75 | 420102 Казан ш.,<br>Галимҗан Баруди ур., 5й.<br>Usz. Kirov@tatar.ru |
| Казан ш. муниципаль берәмлегенең<br>Мәскәү районы социаль яклау бүлеге | (843)<br>554-00-65<br>554-03-45<br>554-77-71<br>544-02-16<br>554-36-72<br>554-25-23 | 420095 Казан ш.,<br>Галимҗан Баруди ур., 5й.<br>Usz.Moskov@tatar.ru |
| Казан ш. муниципаль берәмлегенең Яңа Савин районы социаль яклау бүлеге | (843)<br>523-75-82<br>523- 73-20 | 420044 Казан ш.,<br>Хөсәен Ямашев проспекты, 37 й.<br>Usz.Novosavin@tatar.ru |
| Казан ш. муниципаль берәмлегенең Идел буе районы социаль яклау бүлеге | (843)<br>224-04-20<br>224-03-00 | 420059 Казан ш.,<br>Рихард Зорге ур., 39 й.<br>Usz.Priv@tatar.ru |
| Казан ш. муниципаль берәмлегенең Совет районы социаль яклау бүлеге | (843)<br>273-18-06 | 420037 Казан ш., Гадел Кутуй ур. 33<br>Usz.SovOR@tatar.ru |

## 2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр | 557-20-02 | mtsz@tatarstan.ru |
| Министр урынбасары | 557-20-07 | mtsz@tatarstan.ru |
| Социаль ярдәм чараларының аудит бүлеге башлыгы | 557-20-86 | Elvira.Pislegina@tatar.ru |

## 3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Социаль үсеш идарәсе башлыгы | 264-77-29 | pisma@tatar.ru». |

Министр в.б. Р.Ф.Вәлиуллов